*Декабрь, 2018*

# *Гимназия сулышы №2*

***25 нче гимназия укучылары газетасы***




## Бәйрәм белән!

Кадерле укучылар, укытучылар һәм гимназия хезмәткәрләре.
Сезне белем йортыбызның егерме биш еллык юбилее белән чын күңелдән котлыйбыз! Укуда, мактаулы эшегездә яңадан – яңа уңышлар телибез.

Гимназия тарихыннан саннар һәм фактлар:

-ачылу вакыты: 1993 ел, 1 сентябрь;

-укучылар саны: элек -2600; хәзер – 1245;

- укытучылар саны: элек-250; хәзер -73 ;

- китапханә фонды: элек 24000; хәзер -26393. 1998 елда 25 нче мәктәп- комплексы гимназия статусын ала.



**Юбилейга багышлап**

Быелгы уку елы гимназиянең юбилей елы. Әлеге истәлекле дата уңаеннан 7декабрьдә актлар залында тантаналы кичә үткәрелде.  Мәктәп



коллективын котларга шәһәр мәгариф идарәсе вәкилләре, мәктәп директорлары, шефлар килгәннәр иде. Гимназиядә озак еллар дәвамында эшләгән мәгариф ветераннарын хөрмәтләп каршы алдылар. Шәһәр мәгариф идарәсе башлыгының урынбасары Рамазанова Айзирәк Рәмзилевна һәм гимназия директоры Гаранина Светлана Владимировна кичәдә катнашучы ветеран укытучыларга һәм гимназия коллективына котлау сүзләрен җиткерделәр. Гимназиядә озак еллар дәвамында эшләүче укытучылар, хезмәткәрләр мактау грамоталары белән бүләкләнде.

Гимназия укучылары һәм укытучылары көче белән әзерләнгән концерт  бик кызыклы булды. Укучылар белән бергә укытучылар башкарган флешмоб килгән кунакларда аеруча зур тәэсир калдырды.Хәйруллина Диләрә



**Күңелле ял иттек**





Декабрьның беренче якшәмбесендә без 7 Д сыйныфы укучылары пейнтбол клубына  бардык. Нәрсә ул пейнтбол ? Пейнтбол безнең тормышка соңгы вакытта килеп кергән актив ял төре.Аны балалар да , олы кешеләр дә үз итте. Уенны махсус саклагыч киемнәр кигәч һәм кирәкле инструктаж тыңлагач башладык. Ике командага бүлендек, буяулы шарлар тутырылган автоматлар белән коралландык та  “атыша “башладык. Командалар ярышы мавыктыргыч булды. Әти-әниләр дә бездән калышмадылар. Саф һавада рәхәтләнеп ял иткәч, тәмле ризыклар белән сыйландык.

Ячменева Анастасия

**Котлыйбыз**

Күптән түгел Түбән Кама экономика һәм идарә итү институтында “Заманча белем бирүдә телләр һәм мәдәни багланышлар” темасына төбәкара фәнни-практик конференция үткәрелде. Безнең гимназиядән 10 сыйныф укучысы Якупова Гүзәл “Сөйләм нормаларының бозылуына китергән сәбәпләр” темасына чыгыш ясады. Аның чыгышы I дәрәҗә диплом белән бәяләнде. Гүзәлгә һәм укытучысы Осипова Гөлчәчәк Талип кызына яңадан- яңа уңышлар телибез! Бакирова Алия



**Экскурсиягә бардык**

Соңгы вакытларда безнең шәһәрдә яңа заманча биналар күп төзелде. Шундыйларның берсе- Шинниклар урамында урнашкан Түбән Кама шәһәр суды бинасы.Менә шунда без бер төркем 10 сыйныф укучылары укытучыбыз Вәлиева Ләйсән Рафис кызы белән экскурсиягә бардык.

Хөкемдарлар (судьи) бик җаваплы һөнәр ияләре.Студентлар урамындагы элекке суд бинасы белән чагыштырганда, яңа бинада нәтиҗәле эш өчен барлык шартлар бар. Биредә



заманча җиһазландырылган 22 зал урнашкан. Суд бинасы өч зонага бүленгән: аларның берсе – җәмәгатьчелек, икенчесе – хезмәткәрләр,өченчесе – сак астында булучыларны йөртү өчен хезмәт итә. Кешеләрдән гаризаларны махсус “тәрәзә” аша кабул итәләр икән. Хөкемдарларның көндәлек эшләре турында кызыклы лекция тыңладык.
Экскурсия безгә ошады. Берничә сыйныфташыбыз киләчәктә хокук белгечлеге һөнәрен сайларга булдылар.
Якупова Гүзәл



**Кыш Бабайлар ролендә**

Яңа ел алдыннан Түбән Кама телерадиокомпаниясе “Кыш бабай бүләге” акциясе үткәрде. Бу турыда безгә сыйныф җитәкчесе Аслямова Гүзәл Заһретдин кызы сөйләде. Без авыр хәлдә калган гаиләләрдә яшәүче балалар, шәһәрнең балалар йортында тәрбияләнүчеләр, инвалид балалар турында ишетеп беләбез. Өйдә әти-әниләр белән сөйләштек. Алар бик теләп риза булдылар. Кемдер йомшак уенчык, кемдер шоколадлар, кемдер уку-язу әсбабы алып килде. Берничә көннән бүләкләрне телерадиокомпаниягә алып киттек. Анда безне җылы каршы алдылар. Бүләкләрне җаваплы хезмәткәрләргә тапшырдык, балаларга Яңа ел теләкләрен әйттек. Соңыннан яңалыклар студиясендә фотога төштек. Шавкина Валерия



## 2019 елга йолдызнамә



**Кытай календаре буенча, 2019 - Сары Җир Кабаны елы. Астрологлар әйтүенчә, Кабан елы зур мөмкинлекләр һәм куанычлы яңалыклар алып киләчәк..**

**Кучкар.** Сезнең өчен уңышлы ел. Курыкмыйча яңа проектларга тотына аласыз. Гаиләгездә иминлек, тынычлык булачак.

**Үгезбозау.** Сезне күңелле сәяхәт, гаиләгез белән бергә ял итү көтә. Укуда яки эштә зур мөмкинлекләр ачылырга тора.

**Игезәкләр.** Юлдашларыгыз – уңыш һәм илһам. Яшеренеп яткан талантыгызга юл ачылачак. Бар да яхшы булыр.

**Кысла.** Юлыгызда талантлы һәм кызыклы шәхесләр очрар. Яңа танышлык сезнең файдага булачак.

**Арыслан.** Карьера үсеше, җиңү һәм мәхәббәткә күмелгән ел килә. Җанга рәхәтлек бирүче хисләргә төрелерсез. Бәхәскә кергәнче, компромисслар эзләвең хәерлерәк.

**Кыз.** Иҗади эзләнүләр, яңа идеяләр бөтереп алыр. Ниятләрегезне




тормышка ашыру мөмкинлеге дә килеп чыгар. Барысы да сезнең кулда.

**Үлчәү.** Үзгәрешләр елы. Ул укуда гына түгел, дусларыгызга да кагыла. Тормышны үзегез теләгән якка бора алырсыз.

**Чаян.** Йолдызлар яңалыклар вәгъдә итә. Дөньяга карашыгыз үзгәрер, максатларга ирешүдә киртәләр булмас.

**Укчы.** Хыяллар тормышка ашар чак. Иҗат потенциалыгыз артыр, сәләтләрегезне күрсәтү форсаты чыгар. Яңалыклардан баш тартмагыз.

**Кәҗәмөгез.** Барысы да үз тәртибе белән барганны яратсагыз да, язмыш көтелмәгән, күңелле сюрпризлар әзерли. Ел позитив дулкында узар.

**Сукояр.** Быелгы танышлык, дуслык – озын гомерле. Йолдызлар сезгә нәкъ менә шундый яңа танышулар вәгъдә итә.

**Балык.** Уңышлы ел – нәтиҗәле дә, шатлыклы да. Вак-төяк мәшәкатьләр булса да, тулаем алганда бар да яхшы, хәтта искиткеч яхшы.

Редактор: Якупова Г.Проект җитәкчесе: ШараповаН,Н. Хөрмәтле укучылар, яңалыкларыгыз , тәкъдимнәрегез булса 3023001035@edu.tatar.ru электрон адресына җибәрә аласыз.